РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КОРСАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422051, Республика Татарстан, Сабинский район, село Корсабаш, ул. Школьная, 28
тел. (84362) 2-27-49

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУРСАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422051, Татарстан Республикасы, Саба районы, Курсабаш авылы, Школьная урамы, 28 йорт
тел. (84362) 2-27-49

e-mail: Korsab.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 28.10.2024 — КАРАР №8п

**Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең Курсабаш торак пункты гражданнарының үзара салым акчаларыннан файдалану турында җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге башлыгы карар бирә:

1. 2024 елның 12 ноябрендә 16.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең Курсабаш торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Саба районы, Курсабаш авылы, Школьная урамы, 28 йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең Курсабаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Курсабаш торак пунктында вак таш белән капланган җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын чокырларны ремонтлау - вак таш сатып алу, ташу, салу, эшләр өчен шартнамә буенча түләү)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны "Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/korsabash адресы буенча кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә бастырып чыгарырга һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы А.Р. Гыймадиев